**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 1 августындагы 3253 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 29 маендагы 1529 номерлы карары белән расланган «Молодежный» территориясенең бер өлешен планлаштыру проектына үзгәреш кертү турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 һәм 46 статьяларына таянып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 17 гыйнварындагы 14 номерлы карарлары нигезендә, «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенең 2023 елга муниципаль биремен исәпкә алып **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 29 маендагы 1529 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 25 апрелендәге 1181 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Молодежный» территориясенең бер өлешен планлаштыру проектына, аның аерым өлешен әлеге карарның кушымтасы нигезендә раслау юлы белән, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 1 августындагы
3253 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 29 маендагы 1529 номерлы карары белән расланган «Молодежный» территориясенең бер өлешен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәреш**

«Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру турында, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмә» дигән III бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7. Урам-юл челтәре төзү өчен мәҗбүри алу яки резервлау планлаштырыла торган җир кишәрлекләре исемлеге һәм алар турында белешмәләр

| № т/б | Объектның кадастр номеры, билгеләнеше, исәп номеры | Мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Мәҗбүри алу/резервлау |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:16:120601:2736 | 4200 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |
| 2 | 16:16:120601:11719 | 5440 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Тулысынча |
| 3 | 16:16:120601:17628 | 32759 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |
| 4 | 16:16:120601:21907 | 16870 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |
| 5 | 16:16:120601:4447 | 7709 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |
| 6 | 16:16:120601:4446 | 31904 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә» |

___________________